# Жыр - кешенең канаты

Җыр ул көйгә салынган шигъри әсәр. Җыр – татар халкының иң таралган, иң хөрмәтле иҗат җимеше. Җыр туа, җыр яши, җырлаучысы булганда – җыр мәңге яши. Җыр ул – яшәү чарасы. Җыр – ул халыкның җаны.

**Татар халкының җыр хәзинәсе үзенә күрә бер тарих ул. Анда без ерак гасырлар тавышын да, бүгенге көннәр аһәңен дә ишетәбез. Җыр мирасы – татар халкының бетмәс-төкәнмәс рухи хәзинәсе, күңел көзгесе ул.**

Халык җырны юлдаш һәм сердәш дип, сабак һәм васыять дип атый. “Җыр – эшнең камчысы”, “көй-күңелнең моңы” дигән әйтемнәр яши. Кеше, үзенең көндәлек тормышында, сагыш, кайгыдан арынасы, яки, киресенчә, эченә сыймаган шатлыгын, куанычын белдерәсе килсә, җырлап җибәрә.




Җыр – ул рухлану, җыр – ул матурлыкка соклану. Җыр кешенең юлдашы. “Җырсыз кеше – канатсыз кош” – ди халык.

**Җыр яраткан кеше матурлыкны ярата. Ул нечкә күңелле, мәрхәмәтле була. Ә нечкә күңелле, матурлыкны яраткан кеше беркайчан да начарлык эшләми. Ул кешеләрне ярата, чит җирләрдә яшәгәндә дә туган ягын сагынып яши, йомшак бәгырьле кеше ярдәмчел, мәрхәмәтле була.**

**Бары да үтә,**
**Бары да онытыла**
**Байлык, зурлык, китә югала…**
**Тик җыр үлми**
**Күчеп буыннарга**
**Киләчәктә яшәп җыр кала…**

# Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!